**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2026 елның 24 июнендәге 2153 номерлы карары**

**Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны**
**карап тоткан өчен түләү күләме турында**

Россия Федерациясе Торак кодексының 156, 158 статьялары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы «Күпфатирлы йортта уртак милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм Күпфатирлы йортта уртак милек белән идарә итү, аны карап тоту һәм ремонтлау буенча сыйфатсыз һәм (яки) билгеләнгән вакыттан артып китүче өзеклекләр белән хезмәт күрсәтү һәм эшләр башкару очрагында торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен раслау турында»гы карары нигезендә **карар бирәм**:

1. Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы фатир хуҗаларына торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен (кушымта) расларга һәм 2026 елның 1 июленнән гамәлгә кертергә.

2. Социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарын наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы фатир хуҗаларына күпфатирлы йортта гомуми милектән файдаланганда һәм аны карап тотканда кулланыла торган, торак урынны карап тоткан өчен түләү күләменә керә торган коммуналь ресурслар өчен түләү күләме Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йорт белән идарә итүче оешма тарафыннан билгеләнә дип гамәлгә кертергә.

3. Казан шәһәре Башкарма комитетының район администрацияләренә (Р.Х.Шәмсетдинов, А.И.Салихов, В.В.Жаворонков, Р.Р.Фәтхетдинов) һәм Казан шәһәре Башкарма комитетының Торак-коммуналь хуҗалык комитетына (И.М.Хисмәтуллин) күпфатирлы йортта торак урыннарны карап тоту буенча күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген һәм түләү күләмен билгеләү мәсьәләләре буенча җыелышлар уздырганда торак урын хуҗаларына методик һәм консультация ярдәме күрсәтергә.

4. Күпфатирлы йортта торак урынны карап тоткан өчен түләү күләме күрсәтелә торган хезмәтләрнең составына, күпфатирлы йортның конструктив һәм техник үзенчәлекләренә карап исәпләнә һәм үзгәрә дип билгеләргә.

5. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2025 елның 18 июнендәге 1843 номерлы «Казан шәһәренең торак фондында торак урыннарны карап тоткан өчен түләү күләме турында»гы карарын гамәлдән чыккан дип танырга.

6. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru), Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Казан шәһәре Башкарма комитеты Җитәкчесе урынбасары И.Ә.Гыйниятуллинга йөкләргә.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**

Казан шәһәре
Башкарма комитетының
2026 елның 24 июнендәге
2153 номерлы карарына
кушымта

**Социаль наем килешүләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем килешүләре буенча торак урыннарны яллаучыларга, шулай ук күпфатирлы йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында һәм (яки) гомуми җыелышта торак урыннарны карап тоту өчен түләү күләмен билгеләү турында карар кабул итмәгән күпфатирлы йортлардагы фатир хуҗаларына торак урыннарны карап тоту өчен 2026 елның 1 июленнән күрсәтелә торган хезмәтләрнең төрләре буенча түләү күләме**

| № т/б | Түләүнең аталышы | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Күрсәтелә торган хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) |
|---|---|---|---|
| 1 | Күпфатирлы йорт белән идарә итү | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 6,27 |
| 2 | Күпфатирлы йортның гомуми милке составына керә торган гомуми файдалану урыннарын карап тоту, шул исәптән:<br>- йорт эчендәге гомуми файдалану урыннарын җыештыру;<br>- йорт яны территориясен җыештыру;<br>- чүп үткәргечне карап тоту;<br>- дератизация (дезинсекция);<br>- контейнер мәйданчыкларын карап тоту | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | <br><br><br>3,87;<br><br>6,83;<br>1,07;<br>0,23;<br>0,48 |
| 3 | Биналарның төзелеш корылмаларына, инженерлык системаларына һәм башка гомумйорт милкенә техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау, шул исәптән:<br>- торак бинаны;<br>- лифтларны;<br>- телевидениене күмәк кабул итү системаларын; | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | <br><br><br><br>6,43;<br>6,07;<br>0,70; |

| № т/б | Түләүнең аталышы | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Күрсәтелә торган хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум) |
|---|---|---|---|
| | - күмәк (гомумйорт) исәпләү приборлары белән җиһазландырылмаган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын;<br>- салкын суны исәпләү буенча күмәк (гомумйорт) приборлары белән җиһазландырылган һәм кайнар суны исәплəү буенча күмәк (гомумйорт) приборлары белән җиһазландырылмаган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын;<br>- салкын суны исәпләү буенча күмәк (гомумйорт) приборлары белән җиһазландырылмаган һәм кайнар суны исәпләү буенча күмәк (гомумйорт) приборлары белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын;<br>- салкын һәм кайнар суны исәпләү буенча күмәк (гомумйорт) приборлары белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын;<br>- салкын суны исәпләү буенча күмәк (гомумйорт) приборы һәм җылылык алмашу җайланмалары белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын;<br>- салкын суны исәпләү буенча күмәк (гомумйорт) приборы, җылылык алмашу җайланмалары һәм басымны күтәрә торган насос станциясе белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын;<br>- күмәк (гомумйорт) исәпләү приборлары белән җиһазландырылмаган һәм басымны күтәрә торган насос станциясе белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын;<br>- күмәк (гомумйорт) исәпләү приборлары белән җиһазландырылмаган һәм җылылык алмашу җайланмалары белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын; | | 4,14;<br>4,49;<br>4,99;<br>5,34;<br>5,77;<br>6,15;<br>4,52;<br>5,42; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 4 | - күмәк (гомумйорт) исәпләү приборлары белән җиһазландырылмаган һәм җылылык алмаштыру җайланмасы һәм басымны күтәрә торган насос станциясе белән җиһазландырылган йорт эчендәге су белән тәэмин итү һәм канализация системаларын;<br><br>- җылылык энергиясен исәпләү буенча коллектив (гомумйорт) приборлары һәм җылылык чыгымын автомат рәвештә көйләү системалары белән җиһазландырылмаган йорт эчендәге үзәк җылылык системаларын;<br><br>- җылылык энергиясен исәпләү буенча коллектив (гомумйорт) приборлары белән җиһазландырылмаган һәм җылылык чыгымын автомат рәвештә көйләү системалары белән җиһазландырылган йорт эчендәге үзәк җылылык системаларын;<br><br>- җылылык энергиясен исәпләү буенча коллектив (гомумйорт) приборлары белән җиһазландырылган һәм җылылык чыгымын автомат рәвештә көйләү системалары белән җиһазландырылмаган йорт эчендәге үзәк җылылык системаларын;<br><br>- җылылык энергиясен исәпләү буенча коллектив (гомумйорт) приборлары һәм җылылык чыгымын автомат рәвештә көйләү системалары белән җиһазландырылган йорт эчендәге үзәк җылылык системаларын;<br><br>- йорт эчендәге электр белән тәэмин итү һәм электр җиһазлары челтәрләрен;<br><br>- күпфатирлы йортларда йорт эчендәге газ җиһазлары системаларын;<br><br>- газ җиһазлары гомуми файдалану урыннарында урнаштырылган күпфатирлы йортларда йорт эчендәге газ җиһазлары системаларын (мәсәлән, элек тулай торак сыйфатында файдаланылган йортлар һ.б.);<br>- янгынга каршы эчке суүткәргечнең автомат янгын сигнализациясе системаларын;<br>- җилләтү каналларын;<br>- төтен юлларын | | 5,80;<br><br>3,35;<br><br>4,15;<br><br>4,20;<br><br>5,00;<br><br>2,12;<br><br>0,35;<br><br>0,48;<br><br>2,39;<br><br>0,53;<br>0,94 |

| №<br>т/б | **Түләүнең аталышы** | **Түләү алына торган үлчәү берәмлеге** | **Күрсәтелә торган хезмәтне үлчәү берәмлеге өчен тариф (сум)** |
|---|---|---|---|
| | Йорт эчендәге газ җиһазларын техник диагностикалау (түләүне исәпләү диагностикалауны үткәрү вакыты башланганчы 12 ай эчендә башкарыла) | Торак урынның гомуми мәйданының 1 кв.метрыннан аена | 1,40 |

Искәрмә. Тарифлар өстәмә бәягә салымны исәпкә алып билгеләнгән.

________________________